КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 ноябрь г.Казань № 924

Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законын тормышка ашыру максатларында һәм «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге ФЗ-294 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән 10 көн эчендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 ноябрь, 924 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру
ТӘРТИБЕ

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге ФЗ-294 номерлы Федераль закон (алга таба – ФЗ-294 номерлы Федераль закон), «Социаль яклауда аеруча мохтаҗ булучы гражданнар һәм инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында»
2006 елның 24 июлендәге ТРЗ-60 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне (алга таба – тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү) оештыруны һәм гамәлгә ашыруны җайга сала.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган барлык төшенчәләр ФЗ-294 номерлы Федераль законда бирелгән мәгънәләрдә кулланыла.

3. Тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү максаты – юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – эш бирүчеләр) тарафыннан инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау.

4. Тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

II. Тикшерүдә тотуны һәм күзәтчелек итүне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләр

5. Тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү объектлары – үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы, хезмәткәрләрнең уртача саны кимендә 35 кеше тәшкил иткән һәм инвалидларны эшкә кабул итү

өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә квота билгеләнгән эш бирүчеләр.

6. Тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү предметы – эш бирүчеләр тарафыннан инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итү йөкләмәләрен үтәү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән таләпләрне үтәү, шулай ук вәкаләтле органның вазыйфаи заты күрсәтмәләрен үтәү, гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян салуны булдырмау, мондый зыян салуның нәтиҗәләрен бетерү чараларын үткәрү.

7. Тикшерүдә тотуны һәм күзәтчелек итүне гамәлгә ашыру нәтиҗәсе – эш бирүченең халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарны бозулары булу яки булмау.

8. Тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

эш бирүчеләрне план буенча (документларны карап һәм (яки) барып) һәм планнан тыш (документларны карап һәм (яки) барып) тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү;

инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын, шулай ук эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган тикшерүдә тоту чараларын оештыру һәм үткәрү;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән күздә тотылган һәм ачыкланган бозуларны кисәтү һәм (яки) бетерү буенча чаралар күрү;

эш бирүчеләр тарафыннан инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән таләпләр үтәлеше торышын анализлау һәм фаразлау.

9. План буенча һәм планнан тыш тикшерүләр вәкаләтле орган җитәкчесенең яки урынбасарының (министр яки министр урынбасарының) эш бирүчене тикшерү үткәрү турындагы боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә үткәрелә.

10. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең эш бирүче тарафыннан үтәү вакыты чыгу;

2) вәкаләтле органга түбәндәге фактлар турында кергән гражданнар, шул исәптән эш бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматны карап тикшерү яки алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган вазыйфаи затының мотивлаштырылган гаризасы:

гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян салу куркынычы барлыкка килү;

гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә зыян салу;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушулары нигезендә һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы прокурор таләпләре нигезендә басылып чыккан вәкаләтле орган боерыгы (күрсәтмәсе).

11. План буенча тикшерүләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль тикшерү органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары белән расланган Дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль тикшерү органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен исәпкә алып вәкаләтле орган тарафыннан эшләнә һәм раслана торган еллык план нигезендә үткәрелә.

12. Тикшерү (документларны карап һәм (яки) барып) үткәрү вакыты 20 эш көненнән дә артыграк була алмый.

13. Кече предприятиегә карата план буенча барып тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты 50 сәгатьтән дә артыграк була алмый.

14. Кече эшмәкәрлек субъектлары булып торган эш бирүчеләргә карата план буенча барып тикшерүләр үткәргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу кирәк булган очракта, тикшерү вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган, әмма 10 эш көненнән дә артыграк булмаган вакытка туктатылып торырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рәхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору вакыты гамәлдә булу чорында кече эшмәкәрлек субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, урыннарында, башка объектларында вәкаләтле орган вазыйфаи затларының әлеге тикшерүгә бәйле булган гамәлләре туктатыла.

15. Катлаулы тикшерүләр үткәрү кирәк булуга бәйле булган аерым очракларда, вәкаләтле органның план буенча барып тикшерүләр үткәрүче вазыйфат затының мотивлаштырылган тәкъдимнәре нигезендә, аны үткәрү вакыты вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан озайтылырга, әмма 20 эш көненнән дә артыграк булмаган, кече предприятиеләргә карата 50 сәгатьтән дә артыграк булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

16. Эш бирүченең план буенча тикшерүләре өч елга бер тапкыр (аннан да ешрак түгел) үткәрелә

17. Вәкаләтле органның тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт тикшерүен (күзәтчлеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның
30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә акт төзелә.

18. Эш бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә кабул итү буенча эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән таләпләр бозуларны тикшергәндә ачыкланган очракта, вәкаләтле органның тикшерү үткәргән вазыйфаи затлары Россия

Федерациясе законнары белән күздә тотылган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләргә бурычлы:

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарны рөхсәт ителгән бозуны бетерү турында һәм (яки) кешеләр тормышына, сәламәтлегенә зыян салуны бетерү чараларын, шулай ук федераль законнар белән күздә тотылган башка чараларны үткәрү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмә бирергә;

административ хокук бозу турында беркетмә төзергә;

ачыкланган бозуларны бетерүне тикшерүдә тоту, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә мөмкин булган зыян салуны кисәтү, бетерү буенча чаралар күрергә.

19. Тикшерү вакытында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә эш бирүченең эшчәнлегендә гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры зыян салу куркынычы булу билгеләнгән очракта, вәкаләтле орган Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә мондый зыян салуны булдырмау яки зыян салуны туктату буенча кичектермәстән чаралар күрергә һәм зыян салу куркынычы булу һәм аны бетерү ысуллары турында эш бирүчеләргә, гражданнарга теләсә нинди уңайлы ысул белән ирештерергә тиеш.

20. Вәкаләтле орган ел саен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт тикшерүен (күзәтчлеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру һәм мондый тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 5 апрелендәге 215 номерлы карары белән расланган Тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт тикшерүен (күзәтчлеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру һәм мондый тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү кагыйдәләр нигезендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне гамәлгә ашыру турында доклад әзерләүне башкара һәм әлеге докладны Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгына кертә.

21. Тикшерүдә тотуны һәм күзәтчелек итүне гамәлгә ашырганда административ процедураларны үтәү вакытлары һәм эзлеклелеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан эшләнә һәм раслана торган административ регламент белән билгеләнә.

## III. Тикшерүдә тотуны һәм күзәтчелек итүне оештыручы һәм гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар хокуклары һәм йөкләмәләре

22. Тикшерүдә тотуны һәм күзәтчелек итүне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда вәкаләтле органның вазыйфаи затлары ФЗ-294 номерлы Федераль

закон, әлеге федераль закон нигезендә басылып чыккан башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән вәкаләтләргә хокуклы һәм йөкләмәләрне үти.

23. Тикшерүдә тотуның һәм күзәтчелек итүнең үтәлешен агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге, мондый тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм даимилеге вәкаләтле орган актлары белән билгеләнә. Агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган хезмәткәре вәкаләтләре вәкаләтле органның структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлары турындагы нигезләмәләрдә билгеләнә.

24. Тикшерү үткәргәндә тикшерүдә тотуны һәм күзәтчелек итүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә бурычлы:

Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, тикшерү үткәрелә торган эш бирүче хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

вәкаләтле орган җитәкчесе яки аның урынбасарының (министр яки министр урынбасарының) аны билгеләп кую нигезендә тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсе яки боерыгы нигезендә тикшерү үткәрергә;

тикшерүне хезмәт йөкләмәләрен үтәгәндә генә үткәрергә, барып тикшерүне хезмәт таныкламасын, вәкаләтле орган җитәкчесе яки аның урынбасарының (министр яки министр урынбасарының) күрсәтмәсен яки боерыгын, ә ФЗ-294 номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлеш белән күздә тотылган очракта, тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турындагы документ күчермәсен күрсәткәндә генә үткәрергә;

җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки эш бирүченең вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашырга яки тикшерүгә кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә каршы килмәскә;

тикшерү үткәргәндә катнашучы җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки эш бирүченең вәкаләтле вәкиленә тикшерүгә кагылышлы мәгълүматны һәм документларны күрсәтергә;

җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки эш бирүченең вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән тикшерү акты белән таныштырырга;

җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки эш бирүченең вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кысаларыда алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

ачыкланган бозулар фактлары буенча кабул ителә торган чараларны билгеләгәндә, әлеге чараларның кешеләр тормышына, сәламәтлегенә мөмкин булган куркынычының бозулар авырлыгына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнар, шул исәптән эш бирүчеләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүне рөхсәт итмәскә тиеш;

эш бирүчеләр аларга карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять биргәндә үз гамәлләренең нигезле булуын расларга;

ФЗ-294 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тикшерүләр үткәрү вакытларын сакларга;

эш бирүчедән Россия Федерациясе законнары белән күрсәтү күздә тотылмаган документларны һәм башка мәгълүматларны таләп итмәскә;

барып тикшерү үткәрә башлау алдыннан җитәкче, башка вазыйфаи зат яки эш бирүченең вәкаләтле вәкиле үтенече буенча аларны административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

эш бирүченең тикшерүләрне исәпкә алу журналы булганда, анда үткәрелгән тикшерү турында язып куюны гамәлгә ашырырга.

25. Тикшерү үткәргәндә тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

барып тикшерү үткәргәндә, хезмәт таныкламасын күрсәтеп, эш бирүчедә булырга һәм вәкаләтле орган җитәкчесенең яки аның урынбасарының (министр яки министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерык күчермәсен бирергә;

план буенча барып тикшерү үткәрүгә тикшерү үткәрелә торган оешма белән гражданлык-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган эксперт оешмаларын, экспертларын җәлеп итәргә;

Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны әлеге документлар һәм һәм (яки) мәгълүмат белән эш итә торган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки дәүләт органы яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалардан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән вакытларда һәм тәртиптә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кысаларында түләүсез, шул исәптән электрон рәвештә соратырга һәм алырга;

тикшерү үткәрү турында күрсәтмә яки боерык кабул ителгәннән соң, эш бирүчедән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратырга, барып тикшерү үткәргәндә, әгәр дә барып тикшерү үткәрү алдыннан документларны карап тикшерү үткәрелмәсә, эш бирүчедән тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган документларны соратып алырга.

## IV. Тикшерү үткәргәндә вәкаләтле орган, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

26. Вәкаләтле орган һәм аның вазыйфаи затлары, әгәр дә тикшерү үткәргәндә тиешле функцияләрне, хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

27. Вәкаләтле орган вазыйфаи затларының хезмәт йөкләмәләрен үтәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт йөкләмәләренең тиешенчә үтәмәү очрагын исәпкә алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм әлеге вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә чаралар күрә.

28. Вәкаләтле органның законнарны бозуда гаепле вазыйфаи затларына карата кабул ителгән чаралар турында мондый чаралар кабул ителгән көннән

10 көн эчендә вәкаләтле орган хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган эш бирүчеләргә карата язма рәвештә хәбәргә итәргә тиеш.

29. Вәкаләтле органның тикшерү үткәргәндә эш бирүчеләрнең хокукларын бозуга китергән вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.